Введено в действие
приказом заведующего
МБДОУ детский сад «Салават купере»
Тукаевского муниципального района
Республики Татарстан
Л.З.Зиятдинова
№304 от 02.09.2019 г.

ДЕТСКИЙ САД
САЛАВАТ
КУПЕРЕ

Рассмотрено и утверждено
на педсовете от 02.09.2019 г.
протокол № 1

# Годовой план
# муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения –
# детский сад «Салават купере»
# Тукаевского муниципального района Республики Татарстан
# на 2019-2020 учебный год

**ПЛАННЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ**


1. Балалар бакчасының визит карточкасы ________________________________ 3

2. 2016-2017 нчы уку елына анализ ________________________________ 4 - 6

3. Балалар бакчасының эш юнәлешләре ________________________________ 6

4. Инструктажлар.Хезмәтне саклау. Хезмәткәрләрнең гомуми жыелышлары.

5. Педагогик оештыру эшләре________________________________ 7

5.1 Педагогик киңәшмәләр ________________________________ 8

5.2.Тәрбия һәм белем бирү эшен тулыландыру________________________________ 9

5.3 Бакча мөдире каршында киңәшмәләр________________________________ 9

5.4 Тәрбияче өчен консультацияләр ________________________________ 10

6. Конкурслар, күргәзмәләр ________________________________ 10

7. Телләр турындагы законны тормышка ашыру________________________________ 10

7.1Дәүләт телләренә өйрәтүдә УМК ны куллану буенча эш планы________ 11

8. Тәрбия һәм белем бирү эшенә җитәкчелек итү һәм контроль ______________ 11

9. Әти-әниләр белән эш ________________________________ 12

9.1 Гомуми әти-әниләр җыелышы ________________________________12

9.2 Авыр гаиләләр белән эш ________________________________ 13

9.3 Әти-әниләр өчен консультацияләр ________________________________ 13

9.4 "Яшь әниләр» мәктәбе ________________________________ 13

9.5 Әти-әниләр комитеты белән эш ________________________________ 13

10. Җәмәгатьчелек белән эш ______________________________________________ 14

10.1. Мәктәп белән берлектә эш планы ________________________________ 14

10.2. Методик эш ____________________________________________________ 14

10.3. Шефлык эше ___________________________________________________ 15

11. Административ - хуҗалык эшләре ______________________________________ 15

12.Сәламәтләндеру,чыныктыру планы ______________________________________ 15

13. Юл кагыйдәләрен ойрәту буенча эш планы ______________________________ 16

14. Табигатьне саклау буенча эш планы ___________________________________ 16

## 1.Балалар бакчасының визит карточкасы

Адресы: 423883, Татарстан Республикасы, Тукай районы,Мерәс авылы,

Сәйдәшев урамы, йорт № 24/1

Телефоны: 37-89-64

Балалар бакчасында барлыгы 1 төркем эшли, аларда 9 бала тәрбияләнә, шулардан:

| **Балалар саны** | **Яше** | **Юнәлеше** |
|---|---|---|
| 1 бала | 1-2 (иртә яшь төркеме) | Гомуми үстерелешле (татар) |
| 1 бала | 2-3 ( 1 нче кечкенәләр) | Гомуми үстерелешле (татар) |
| 1 бала | 3-4 (2 нче кечкенәләр) | Гомуми үстерелешле (татар) |
| 1 бала | 4-5 (уртанчылар) | Гомуми үстерелешле (татар) |
| 3 бала | 5-6 (зурлар) | Гомуми үстерелешле (татар) |
| 2 бала | 6-7 (мәктәпкә әзерлек) | Гомуми үстерелешле (татар) |

**Хезмәткәрләр һәм белгечләр турында мәгълүмат:**

Балалар бакчасында 4 хезмәткәр эшли.

Шуларның 1се педагог.

**Балалар бакчасы тәрбиячесе:** Сайфуллина Ләйсән Марсель кызы

Педагог  татар һәм рус телләрендә иркен аралаша.

***Хезмәт стажы:*** 24 ел, тәрбияче булып 23 ел эшли

***Белеме буенча:***

Махсус урта  белемле

***Категория буенча:***

Югары  категория

**Балалар бакчасы мөдире:** Зиятдинова Лилия Загит

Белеме – югары ,татар теле һәм әдәбияты белгечлеге буенча

Эш стажы – 1ел

Административ эш стажы – 1 ел

**2. 2018-2019 нчы уку елына анализ**

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе “Салават күпере” балалар бакчасы 1 катлы аерым бинада урнашкан, 10,5 сәгатьлек (7.00-16.00 дүшәмбе-җомга) эш көннәре белән эшли. Бакчада 1 төркем, 20 урынга исәпләнгән.

Коллектив үз алдына түбәндәге бурычларны куеп эшләде:

-Балаларга рус һәм татар телләрен өйрәтүнең сыйфатын үстерү.
-ФГОС ны исәпкә алып балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү процессында яңа технологияләр, яңа алымнар куллануны дәвам итү,ныгыту.
-Балалар бакчасы һәм мәктәп арасында арадашлык булдыру.
-Балаларга юл кагыйдәләрен өйрәтүне дәвам итү,ныгыту .
Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү эше түбәндәге программалар һәм методик кулланмаларны кулланып башкарылды:

1. Балалар бакчасының гомуми белем бирү программасы.
2. Общеобразовательная программа “От рождения до школы” Н.Е. Вераксы, М.А.Васильевой, Т.А.Комаровой)

3. “Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы” Р.К. Шаехова.

4. «Гаиләдә балалар бакчасында әдәплелек тәрбияләү программасы» К.В.Закирова, Р.А.Низамова, 2005.

5. «УМК по обучению двум государственным языкам» Зариповой З.М., Гафаровой С.М., Хазратовой Ф.В., 2012.

МБМББУ “Салават күпере” балалар бакчасы 2016-2017 нчы уку елы өчен төзелгән еллык план нигезендә ел дәвамында системалы эш алып барды. Балалар бакчасында уку елы дәвамында 9 бала тәрбияләнде.

Тәрбияче тарафыннан балалар бакчасының укыту – тәрбия планнары, шөгыльләр елтәре һәм календарь планнары төзелде, бакча мөдире тарафыннан расланды һәм гамәлгә кертелде. Ел дәвамында шул расписание буенча тәрбияче даими рәвештә балалар белән шөгыльләр алып барды.Мәктәпнең башлангыч сыйныф укытучылары белән ныклы элемтәдә торабыз: алар елга берничә тапкыр балалар бакчасына шөгыльләр карарга киләләр, гомуми киңәшмәләрдә, ата – аналар җыелышларында катнашалар.

Уку елы ахырына тәрбияче үзенең иҗади эшләренең, балаларга ясалган диагностикалар нәтиҗәсенең тиешле дәрәҗәдә булуларына иреште.

МБМББУ “Салават купере” балалар бакчасы татар балаларына рус теленә өйрәтү С.М.Гаффарованың “Изучаем русский язык” программасы нигезендә алып барыла.

Уку елы дәвамында 4 педагогик киңәшмә үткәрелде. Бу киңәшмәләрдә балаларның физик, психик, социаль үсешенә кагылышлы актуаль мәсьәләләр һәм кече яшьтәге балаларның бакчага ияләшү соруалары, физик сәламәтләндерү эшләрен һәм халык традицияләренә , милли гореф-гадәтләренә нигезләнеп, әхлакый хисләр тәрбияләүне оештырулар, ФГОС һәм УМК таләпләренә туры китереп тәрбия-белем бирү эшен яңартулар каралды. УМКны куллану өчен 1 ноутбук, 1 экран һәм 1 мультимедейный аппаратура бирелде, күрсәтмәлелекләр ламинадландырылып бетерелде, төркемдә әти-әниләр өчен стендлар булдырылды, татар телендә мультфильмнар карау оештырылды, перспектив һәм көндәлек планнар системалаштырылды.Балалар бакчасының төркем бүлмәсе һәм үсеш тирәлеге шушы программаларның таләпләренә туры килерлек итеп яңартылды. Барлык бүлмәләр һәм почмаклар да рациональ файдаланыла.

Тәрбия һәм өйрәтү эшенең системалы баруын,балаларга сыйфатлы белем бирүне күзәтү максатыннан тәрбияче белем бирү эшчәнлекләрен күрсәтте.Үткәргән белем бирү эшчәнлекләре ФДББТга нигезләнеп дөрес методик таләпләргә туры килеп үтте.Ел дәвамында тәрбиячебез төрле дәрәҗәләрдә уткәрелгән семинарларда һәм педагогик конференцияләдә катнашты.

Балалар бакчасында әти-әниләр белән эш төрле формаларда алып барылды: анкеталар үткәрелде, актуаль темаларга консультацияләр бирелде, стендлардагы мәгълүматлар тулыландырылды, ачык ишекләр көне, бердәм бәйрәмнәр күңел ачулар үткәрелде. Әти-әниләр белән бергә җыелышлар үткәрелде.

Ел ахырында төркем тәрбиячесе тарафыннан тәрбия һәм белем бирү программасының үтәлешен билгеләү максатыннан мониторинг үткәрелде. Мониторинг нәтиҗәләре Балалар бакчасының гомуми белем бирү программасына нигезләнеп ясалды.

Балалар бакчасында апрель аенда үткәрелгән мониторинг түбәндәге нәтиҗәләрне күрсәтте.

| | Уртанчылар төркеме | Зурлар төркеме | Мәктәпкә әзерлек төркеме |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Югары** | 73 % | 93 % | 100 % |
| **Уртача** | 27 % | 7 % | - |
| **Түбән** | - | 1,1 | - |

Балаларны сәламәт рухта тәрбияләү – балалар бакчасының изге бурычы, чөнки балаларның күп вакыты бакчада уза, ул аларның икенче өе булып тора. Шунлыктан бакчада нәниләр өчен барлык уңай шартларны тудырырга тырыштык. Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм интеллектуаль үсешен тәэмин итү йөзеннән, эшебезне планлаштырудан башладык, планнарны балалар бакчасының эшен камилләштерү буенча үзгәрешләр кертеп һәм яңа бурычлар куеп оештырдык. Яшь үзенчәлекләренә туры китереп һәр төркемдә чыныктыру планы төзелде, аның буенча эш оештырылды; сәламәтлек почмагы, экскурсияләр оештырылды, анда дару үләннәре турында әңгәмәләр үткәрелде, үләннәрне танырга өйрәтелде; хәрәкәтле уеннар ечен кулланма жиһазлар тупланды; спорт төрләрен кулланып бәйрәмнәр, хәрәкәтләнү күнекмәләрен үстеру буенча күңел ачу кичәләре уздырылды. Тәрбияче көндәлек режимны төгәл үтәп, белем-тәрбия бирү эшен дөрес оештырды. Иртәнге гимнастика, физкультура занятиеләре ел буена программага нигезләнеп, тиешле дәрәҗәдә алып барылды. Физкультура дәресләрендә иң беренче балаларның активлыгына игътибар ителде, дәрес уздыру төрләре үзгәртелде, яңалыклар кулланылды. Бу юнәлештәге эшнең нәтиҗәсе ата-аналардан да бәйле. Без аларга сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру принципларын өй шартларында да үтәү кирәклеген искәртеп тордык.

Бакчада ел буена көндәлек режим төгәл үтәлде, йоклар алдыннан аяк кулларны юу, йокыдан торгач балаларның күңелен күтәрү, чыныктыру күнегүләре эшләтелде. Төркемдә буш вакытларда даими рәвештә күз гимнастикасы, аваз әйтү гимнастикалары кертелде. Кыш көне шуар өчен бакча ишегалдында балалар белән бергәләшеп кардан тау ясап куйдык. Кар сыннары ясау буенча район күләмендә конкурста катнаштык..

Бала иң беренче чиратта үзе яшәгән төбәкнең экологик хәлен белергә тиеш, шуның өчен төркемедә һәр ел фасылында табигатькә экскурсияләр оештырылды. Балалар табигатьнең төрле халәтен, бөҗәкләрне, чәчәкләрне, күк йөзен күзәттеләр, яфраклар, дару үләннәрен җыйдылар, бакча мәйданчыгын чүпләрдән арындырдылар, хайваннар белән таныштылар. Күзәтү, хезмәт аша балалар табигатьнең чисталыгын сакларга, матурлыгын күрә белергә өйрәнделәр.Язын тирә-якны чистартып, апрельдә чәчәк рассадалары утыртып каршыладык. Бакчадагы язгы эшләр белем-тәрбия бирү эшләре белән чиратлап алып барылды: язгы су юлларын ачу, стена буендагы карны чистарту, бакча мәйданын җыештыру уздырылды, чәчәкләрне тәрбияләп үстерү, сирәкләү, су сибү – болар барысы да бакча хезмәткәрләре тарафыннан эшләнде. Көзне каршылап участоктан чәчәк орлыклары, яфраклар җыйдык, мәйданны коелган яфраклардан

арындырдык. Кышны каршы алганда исә, кардан сыннар ясау, кар көрәү, тубәләрне боздан, кардан арындыру кебек эшләр эшләнде, кошларга җим салыр өчен җимлекләр элдек, аларга җим салуны оештырдык.

Милли һәм бакча традициясенә әйләнгән бәйрәмнәргә дә зур игътибар бирелде, чөнки милли үзаң, милләткә мәхәббәт хисләренә дә нигез мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында салына. Октябрьдә "Сөмбелә" бәйрәме, ноябрь аенда өлкәннәребезгә багышланган "Өлкәннәрне олылыйк!" дигән бәйрәм уздырдык, анда балаларның әбиләрен чакырдык, чәй табыны янында кунак иттек. Декабрь аенда Яңа ел бәйрәменә әзерлек барды һәм бәйрәмне һәр елдагыча бик күңелле итеп үткәрдек.Район куләмендә үткәрелгән "Яңа ел плакаты" конкурсында бакчабыз 2 нче урынны яулады. Мартта һәр елдагыча зурлап, ныклы әзерлек белән, Әниләр бәйрәме,Гаилә бәйрәме, Кошларны каршылау көне уздырылды. Апрельдә Г. Тукай туган көнен уздырдык.Шул уңайдан район китапханәләр челтәре үткәргән Г.Тукай иҗатына багышланган конкурста катнашып Газетдинов Самат 2 нче дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләнде.Яр Чаллы шәһәре китапханәсе уткәргән, "Г.Тукай – туган ягыбыз шагыйре" дип исемләнгән конкурста катнашып, 2 нче урынны Гатиуллин Данил алды. Бөек Җиңү бәйрәменә багышланган митингта катнаштык. Май ахырында "Сау бул, бакча" бәйрәме уздырылды, анда мәктәпкә укырга барырга тиешле балаларны озату үткәрелде.

Май азагында балаларны яклау көненә багышлап "Кече Сабантуй" бәйрәме гөрләп уздырылды.Шулай ук ел дәвамында район күләмендә оештырылган конкурсларда

катнашырга тырыштык:лэпбук,"Профессияләр конкурсы", "Смотр строя и песни" конкурслары, "Балкыш" балалар сәнгать фестиваленең сайлап алу турында катнаштык. Ел да үткәрелеп килүче "Балалар. Техника. Иҗат." күргәзмәсендә кул эшләре күргәзмәсе оештырдык.

Баланы дөрес сөйләргә өйрәтү, аның сүз байлыгын арттыру, үз фикерен башкаларга ачык , аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәтү балалар бакчасының төп бурычы булып тора.Без даими рәвештә шул юнәлештә эш алып барабыз. Моның өчен УМК киң кулланыла, ягъни, без ана телендә мультфильмнар карыйбыз, хикәяләр, әкиятләр укыйбыз һәм балалар белән бергә әчтәлеген сөйлибез,сюжетлы-рольле, хәрәкәтле һәм түгәрәк уеннар уйныйбыз. Җырлар өйрәнәбез , шигырьләр ятлыйбыз. Картиналар буенча хикәяләр төзергә өйрәнәбез. Сәнгатьле сөйләм, кычкырып уку, хикәя төзеп сөйләү кебек эшләрне башкарганда авазларны дөрес әйтү беренче урынга куела.

Белгәнебезчә, бала ана телендә һәм рус телендә камил сөйләшергә өйрәнсен өчен гаиләдә дә эшне дәвам итәргә кирәк. Шуңа күрә без әти-әниләр белән бергәләп эш алып барырга омтылабыз. УМК составына кергән мультфильмнарны өйгә карарга биреп

җибәрәбез. Балалар бакчасында өйрәнгән шигырьләрне ныгыту өчен өйгә алырга тәкъдим итәбез.

Ел дәвамында балалар бакчасының матди - техник хәле яхшырды. Гомумән алганда балалар бакчасының еллык эше тиешле югарылыкта дип нәтиҗә ясалды. Шулай да әле чишелешен табасы проблемаларыбыз да шактый:

- тәрбиячеләрнең һөнәри осталыкларын тагын да камилләштерү таләп итеlә;

- балаларга белем һәм тәрбия бирүне яхшырту максатыннан бакчаның матди- техник хәлен яхшырту;

- балаларның сәламәтлегенә ныклы игътибар итеп, авыру көннәрен киметү өстендә ныклы эш алып барырга.

## 3.Балалар бакчасының эш юнәлешләре:

2019– 2020 нче уку елына бурычлар

1.Тәрбия һәм белем бирү процессын ФГОС нигезендә оештыру
2. Уку-укыту медотик кулланмаларына (УМК) таянып,ике дәүләт теле – рус һәм татар телләрен өйрәтүдә яңа алымнар куллану.
3.Халык педагогикасын куллану
4.Балаларның физик һәм психик яктан сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту
5.Экологик тәрбия бирү

## 4. Инструктажлар,хезмәтне саклау,

## хезмәткәрләрнең гомуми җыелышлары, хезмәт күрсәтүче персонал өчен консультация

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Куркынычсызлык техникасы, хезмәтне саклау, янгын куркынычсызлыгы буенча агымдагы инструктажлар үткәрү. | Ел дәвамында | Бакча мөдире. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | Гомуми җыелыш: | | Бакча мөдире |
| | а) «Хезмәтне оештыру кагыйдәләре» | август | |
| | б) «Куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре үтәлешен тикшерү нәтиҗәләре» | апрель | |
| 4. | Гражданлык оборонасы буенча хезмәткәрләр һәм балалар белән эвакуацияләү тренировкалары үткәрү | квартал саен | Бакча мөдире |
| 5. | Яңа ел чыршы бәйрәмен үткәргәндә техник һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренең үтәлеше | декабрь | Бакча мөдире,тәрбияче |
| 6. | Хезмәтне саклау, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренә инструктаж | Квартал саен | Бакча мөдире |
| 7. | Медицина күзәтүен, диспансеризация тикшерүен үтүне оештыру | график буенча | Бакча мөдире, шәфкать туташы(ФАП) |

## 5. Педагогик оештыру эшләре

### 5.1 Педагогик киңәшмәләр

| № | Үткәреләчәк чаралар, үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|
| | **1 нче педагогик киңәшмә**<br>Август<br>Тема:Яңа уку елын башлау. | (Оештыру киңәшмәсе) |

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Җәйге сәламәтләндерү чорына йомгак ясау | Тәрбияче |
| 2. | 2019-2020нче уку елына төзелгән бердәм еллык календарь графигы, эш планы белән танышу һәм раслау.<br><br>2019-2020нче уку елына төзелгән перспектив планнарны, шөгыльләр челтәрен, көндәлек режимны кабул итү. | Бакча мөдире |
| 3. | Татар балалар бакчасында рус телен укыту үзенчәлекләре | Бакча мөдире<br><br>тәрбияче |
| | **2 нче педагогик киңәшмә**<br><br>Декабрь<br><br>Тема: Балаларның сөйләмен үстерү буенча эшченлекне ФДББС таләпләренә туры китереп тагы да камилләштерү, укыту-методик комплектларга нигезләнеп эшләүне дәвам итү | |
| 1. | Балаларның сөйләмен үстерүдә Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинованың “Туган телдә сөйләшәбез” 2-3 яшь укыту-методик комплектын кулланып эшләүдә үстерешле тирәлек | Мөдир |
| 2. | Балалар бакчасында милли тәрбия. Чыгыш. | Тәрбияче |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| | Укыту методик комплектланы кулланып эшләүдә: дидактик уеннар, методик эшкәртмәләр күргәзмәсе. | Мөдир |
| | **3 нче педагогик киңәшмә**<br>*Март*<br>*Тема:* **“**Халык педагогикасына таянып<br>бала шәхесен һәрьяклап үстерү” | |
| 1. | “Халык педагогикасына таянып күпкырылы шәхес тәрбияләү өчен шартлар тудыру” | Бакча мөдире<br>Тәрбияче |
| | **4 нче педагогик киңәшмә.**<br>***Май***<br>*Тема:*«2019-2020 нче уку елында эшләнгән эшкә нәтиҗә ясау» | |
| 1. | 2019-2020 нче уку елында эшләнгән эшкә нәтиҗә ясау.<br>2019-2020 нче уку елында балаларга белем һәм тәрбия бирү программасының үтәлеше турында тәрбияче отчеты | Бакча мөдире |
| 3. | Балалар бакчасы б/н мәктәп арасында бердәмлек-тәрбиянең нигезе. | Тәрбияче |

## 5.2 Тәрбия һәм белем бирү эшен тулыландыру

| Кабинет, төркем, мәйданчык | Материаллар | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| Методик бүлмә<br>(бакча мөдире бүлмәсе) | 1. Дидактик рәсемнәр булдыру:<br>- Кыргый хайваннар<br>- Агач-куаклар<br>- Кошлар<br>- Чәчәкләр.<br>2. Методик әдәбият туплау.<br>3. Түбәндәге темаларга күргәзмәләр:<br>- Белем көне<br>- Яңа методик кулланмалар<br>- Ел фасыллары. | Сентябрь<br>Ел дәвамы<br>Ел дәвамы | Бакча мөдире<br>Тәрбияче |
| Музыка почмагы | 1. Дидактик уеннар төзү.<br>2. Маскалар ясау.<br>3. Бәйрәмнәр өчен җиһазлар туплау. | Ел дәвамы | Бакча мөдире<br>Тәрбияче |
| Физкультура почмагы | 1. Маскалар ясау.<br>2. Бәйрәмнәр өчен атрибутлар ясау.<br>3. Җиһазларны буяу. | Ел дәвамы | Бакча мөдире<br>Тәрбияче |
| УМК НРК почмагы | 2. УМК буенча дидактик уеннар ясау. | Ел дәвамы | Бакча мөдире<br>Тәрбияче. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 3. Күргәзмә өчен җиһазлар.<br>4. М.Җәлил турында материал туплау.<br>5. Г.Тукай – материал туплау. | | |
| ИЗО почмагы | 1. Документларны яңарту.<br>2. Папкаларны яңарту.<br>3. ФГОС буенча декоратив сәнгать төрләрен туплау. | Ел дәвамы | Тәрбияче. |
| Төркем бүлмәсе | 1. Әти-әниләр почмагын яңарту.<br>2. Сюжетлы – рольле уеннар өчен почмакларны яңарту.<br>3. Танып – белү эшчәнлеге өчен почмакларны яңарту. | Ел дәвамы | Бакча мөдире<br>Тәрбияче |
| Территория | 1. Мәйданчыклардагы җиһазларны буяу, ремонтлау.<br>2. Территорияне,чәчәк газоннарын тәртиптә тоту.<br>3. Комны алыштыру. | Май-август | Хезмәткәрләр |

## 5.3 Бакча мөдире каршында киңәшмәләр.

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Узган елга нәтиҗә,яңа уку елына алынган бурычлар турында фикер алышу | сентябрь | Бакча мөдире |
| 2. | Югарыдан килгән документларны өйрәнү | Ай саен | Бакча мөдире |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | Күңел ачу кичәләре, бәйрәмнәр үткәргәндә хезмәткәрләрнең эшен оештыру | график буенча | Бакча мөдире<br>Тәрбияче |

## 5.4 Тәрбияче өчен консультацияләр.

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | “Балаларның сөйләмен баетуда халык авыз иҗатының роле” | ноябрь | Бакча мөдире |
| 2 | “Төрле режим вакытларында халык авыз иҗатын куллану” | апрель | Бакча мөдире |

## 6. Конкурслар

| Үткәрү вакыты | Тема | Җаваплы |
|---|---|---|
| Октябрь | “ФЭМП буенча иң яхшы дидактик уен” конкурсында катнашу (район) | Тәрбияче Сәйфуллина Л.М. |
| | “Ел тәрбиячесе” конкурсы (район) | Тәрбияче Сәйфуллина Л.М. |
| Декабрь | Конкурс “Тылсымлы кар илендә” (участок. кардан сыннар ясау ата-аналар белән) | Бакча мөдире<br>Фарваева Р.Ә. |
| | Тәрбиячеләр сәнгать фестивалендә катнашу (район) | Тәрбияче<br>Мөдир |
| Февраль | “Профессияләр дөньясы” конкурсы (район) | Тәрбияче<br>Мөдир |

| | | |
|---|---|---|
| Март - апрель | “Лучший билингвальный детский сад” (Республика конкурсы) | Бакча мөдире Фарваева Р.Ә. |
| Январь - март | “Ел тәрбиячесе” конкурсы (республика) | Тәрбияче Мөдир |
| Март | “Смотр строя и песни” бәйгесендә катнашу | Тәрбияче Сәйфуллина Л.М |
| Март | “Балкыш “ фестивалендә катнашу | Тәрбияче Сәйфуллина Л.М |
| Апрель | “Дети.Техника.Творчество” күргәзмәсендә катнашу | Коллектив |
| | “Иң яхшы экология проекты” конкурсы (район) | |
| Апрель | Балаларның кул эшләреннән күргәзмә “Тукай әкиятләрендә кунакта” | Тәрбияче Сәйфуллина Л.М |
| | “Яшел ут – 2018” (ЮЙК) конкурсы (республика) | Тәрбияче Сәйфуллина Л.М |
| | “Иң матур мәйданчык”конкурсы (район) | Коллектив |
| Октябрь,февраль,май, июль | “БиблиоОСЕНЬ”,”БиблиоЗИМА”, “БиблиоВЕСНА”, БиблиоЛЕТО” | Коллектив |
| Апрель | Лепбук конкурсы | Тәрбияче Сәйфуллина Л.М |
| Май | “Смотр строя и песни” конкурсы (район) | Тәрбияче Сәйфуллина Л.М |

## 7. Телләр турындагы законны тормышка ашыру буенча эш планы

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Һәрбер балага ана телендә төрле яклап үсеш алу өчен шартлар тудыру | Ел дәвамында | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 2 | Төркемдә  тәрбия һәм белем бирү эшен туган телдә (татар телендә) оештыру. | Ел дәвамында | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 3 | Дәүләт телләре турындагы законны үтәү максатыннан, балаларга татар һәм рус телләрен өйрәтүне оештыру. | Ел дәвамында | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 4 | Тематик шөгыльләр үткәрү – “Татар телем-анам теле”, “Гаилә гореф-гадәтләре”, “Әбиемнең сандыгы” | кварталга бер | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 5 | Татар халык бәйрәмнәрен, күңел ачу иртәләре, атналыклар үткәрү- “Сабантуй”, “Әниемә бүләгем” һ.б. | Ел дәвамында | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 6 | Габдулла Тукайның туган көненә багышлап шигырь бәйрәме үткәрү, конкурсларда катнашу | Апрель | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 7 | Мерәс авылы  үзәк китапханәсе һәм б/бакчасы  белән б-ның татар телендә китап укуын күтәрү буенча уртак эш алып бару. | Ел дәвамында | Бакча мөдире, тәрбияче |

## 7.1 Дәүләт  телләренә өйрәтүдә УМКны куллану буенча эш планы

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Балаларның белем дәрәҗәсен ачыклау өчен диагностика үткәрү | Октябрь апрель | Тәрбияче |
| 2 | УМК белән бирелгән дидактик әсбапларны, кассеталарны  төркемдә тулылындыру | ел буе | Тәрбияче |
| 4 | Күрсәтмә, таратма материаллар туплауны дәвам итү, яна дидактик уеннар булдыру | ел буе | Тәрбияче |
| 5 | Әти-әниләр почмагындагы мәгълүмат-ларны алыштырып һәм тулыландырып тору | ел буе | Тәрбияче |

## 8.  Тәрбия һәм белем бирү эшенә җитәкчелек итү һәм контроль

### 8.1 Оператив тикшерүләр

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Төркемнең яңа уку елына әзерлеген тикшерү. | Сентябрь | Бакча мөдире |
| 2. | Тәрбияченең  планнарын, документацияләрен. | Октябрь | Бакча мөдире |
| 3. | Төркемдә  үткәрелгән бердәм эшчәнлекләрне анализлау | Ай саен | Бакча мөдире |
| 4. | Балаларның тукландыру графигын | Ноябрь, | Бакча мөдире |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | контрольдә тоту. | апрель | |
| 5. | Төркемнең чыныктыру чараларын үткәрүне тикшерү. | декабрь | Бакча мөдире |
| 6. | Төркемдә культура – гигиена кагыйдәләренең үтәлешен анализлау | Январь, февраль | Бакча мөдире |
| 7. | Иртәнге гимнастиканың системалы һәм программа таләпләренә туры китереп үткәрелүен контрольдә тоту. | Февраль, май | Бакча мөдире |
| 8. | Балалар иртәләрен, музыкаль күңел ачуларны, физкультура мавыктыргыч уеннарны оештыруга һәм үткәрүнгә анализ. | Ел дәвамында | Бакча мөдире |

## 8.2 Тематик тикшерүләр

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | УМК куллану( Использование воспитателем УМК) | январь | Бакча мөдире |

## 9.Әти-әниләр белән эш

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Уку елы башында балаларның өйләрендә булу, гаилә хәлләре белән танышу, бакчага тарту. | сентябрь | тәрбияче, мөдир |
| 2 | Иртән балалар китергәндә һәм кич килеп алганда ата – аналар белән әңгәмәләр, консультацияләр үткәрү. | даими | тәрбияче |
| 3 | “Ачык ишекләр” көне үткәрү. | ноябрь, март | тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 | Юлда йөрү, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен даими искә төшерү. | даими | тәрбияче |
| 5 | Балаларда шәфкатьлелек, әдәплелек, миһербанлылык тәрбияләү. | даими | тәрбияче |
| 6 | Балаларда үз – үзләренә хезмәт күрсәтергә өйрәтүне дәвам итү. | даими | тәрбияче |
| 7 | Бәйрәмнәрдә конкурсларда актив катнашу. | даими | тәрбияче |

## 9.1 Гомуми әти-әниләр җыелышы

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Тема:<br>”Балалар бакчасының 2019-2020 уку елына алынган бурычлары белән таныштыру”. | Октябрь | Бакча мөдире,<br>тәрбияче |
| | Балалар бакчасының 2019-2020 уку елына алынган бурычлары белән таныштыру<br>Әти-әниләр комитеты сайлау | | |
| | Татар балалар рус телен өйрәтү үзенчәлекләре | | |
| | Ата-аналарга консультация”Антикоррупционное воспитание на уровне дошкольного общего образования” | | |
| 2. | Тема: “ Кышкы чорда куркынычсызлык кагыйдәләре” | | |
| | “Икетеллелекне тормышка ашыру буенча балалар бакчасы белән ата- | Декабрь | Бакча мөдире, тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | аналар арасында эшчәнлек” | | |
| | “Авыруны ничек булдырмаска?” | | Бакча мөдире, тәрбияче |
| | Төрлесеннән | | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 3. | Тема: “Уен балага ни өчен кирәк?” | Май | Бакча мөдире, тәрбияче |
| | “Уенның бала тормышындагы әһәмияте” – чыгыш | | Бакча мөдире, тәрбияче |
| | Булачак укучыларның әти-әниләренә киңәшләр. | | Бакча мөдире, тәрбияче |

## 9.2 “Авыр гаиләләр” белән эш планы

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Балаларны тәрбияләүгә салкын караучы гаиләләрне ачыклау һәм күзәтү | Ел дәвамында | Тәрбияче |
| 2 | Ата-аналар комитеты белән “Авыр гаиләләрнең” очрашуын тәэмин итүе һәм әңгәмәләр оештыру | Ел дәвамында | Бакча мөдире, ата-аналар комитеты |
| 3 | Режим, туклану һәм балаларны тәрбияләү буенча консуль-тацияләр, әңгәмәләр оештыру | Ел дәвамында | Бакча мөдире, тәрбияче |

## 9.3 Әти-әниләр өчен консультацияләр

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Грипп һәм ОРВИ профилактикасы. | Октябрь | Тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | Мәктәпкә әзерлек төркеме ата-аналарына ярдәмгә. | Ноябрь | Тәрбияче |
| 4 | “21 февраль – Халыкара туган телләр көне” турында кыскача мәгълүмат. | Февраль | Тәрбияче |
| 5 | “Сезнең балагыз мәктәпкә әзерме?” | Апрель | Тәрбияче |
| 6 | “Профилактика несчастных случаев на воде”ата-аналарга киңәшләр. | Май | Тәрбияче |

## 9.4 “Яшь әниләр ” мәктәбен оештыру

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Балалар бакчасының көнлек режимы турында әңгәмә | Бакчага урнашкан вакытта | Тәрбияче |
| 2 | Баланың бакчага ияләшү вакытын ничек оештырырга | Сентябрь | Тәрбияче |
| 3 | Балалар бакчасында тәрбия эше турында әңгәмә | Квартал саен | Тәрбияче |
| 4 | Кечкенә балаларның дөрес тукландыруның әһәмияте | Декабрь | Тәрбияче |
| 5 | Авыру очракларын булдырмау өчен чыныктыру чараларын куллану | Февраль | Тәрбияче |

## 9.5 Әти-әниләр комитеты белән эш

| № | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Әти-әниләр комитетын оештыру | Сентябрь | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 2. | Бәйрәм иртәләрендә катнашуларын оештыру | Октябрь | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 3. | Балалар бакчасы мөдире белән очрашу, сәламәтләндерү турында әңгәмә үткәрү | Ноябрь | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 4. | Ачык ишекләр көне оештыру | Декабрь, май | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 5. | Участокта  кышкы корылмалар төзергә ярдәм итүне оештыру | Декабрь | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 7. | Участокларда карны чистартуда ярдәм оештыру | Февраль | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 10 | Чәчәк үсентелэре әзерләүдә катнашуны оештыру | Апрель | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 11 | Балалар бакчасы терр. җыештыру. | Май-июнь | Бакча мөдире, тәрбияче |

## 10.  Җәмәгатьчелек белән эшләү

### 10.1.      Мерәс авылы башлангыч белем  бирү мәктәбе һәм “Салават күпере” балалар бакчасының 2019-2020нче  уку елына берләштерелгән планы.

| № | Үткәреләчәк чаралар | Уткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | 1 Сентябрь көнне уку елы башлануга багышланган «Беренче кыңгырау” тантаналы линейкада катнашу | Сентябрь | тәрбияче |
| 2. | Мәктәпнең сыйныф бүлмәләре, китапханә,спорт залы,музей бүлмәләренә экскурсияләр оештыру | Сентябрь | тәрбияче |
| 3. | Мәктәпкә хәзерлек төркемендә «Алдыбызда мәктәп еллары» дигән темага әңгәмә оештыру | Октябрь | тәрбияче |
| 4. | Балалар бакчасында үткәрелә торган бәйрәмнәргә һәм кичәләргә башлангыч сыйныф укучыларын чакыру «Сабантуй», “Әниләр бәйрәме” һ.б. | Ел дәвамында | тәрбиче |
| 5. | Мәктәп белән бергәләп 1-июнь, Республика көннәрен үткәрү | Ел дәвамында | Мөдир |
| | | Ел дәвамында | |

## 10.2.Методик эш

| № | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Башлангыч сыйныфларда уку-укыту буенча директор урынбасары белән мәктәп һәм балалар бакчасы арасында бергәләшеп эшләү планын төзу һәм раслау. | Сентябрь | Бакча мөдире<br>Мәктәп директоры |
| | Мәктәпнең башлангыч сыйныф укыту – чыларынын һәм тәрбияченен узара | Ачык | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | дәресләр һәм шөгыльләр каравын оештыру. | шөгыльләр | Бакча мөдире Директор урынбасары |
| 3. | Башлангыч сыйныф укытучыларын мәктәпкә хәзерлек төркемнәренә йомгаклау шөгыльләренә чакыру. | Май | Бакча мөдире Мәктәп директоры |
| 4. | “Башлангыч сыйныф укучылары бездә кунакта” | Январь | Бакча мөдире Директор урынбасары |

## 10.3 Шефлык эше

| № | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Башлангыч сыйныф укучыларын бергәләшеп уеннар оештырырга чакыру. | Февраль Апрель | Тәрбиче |
| 2. | Укучылар ярдәме белән китаплар ремонтлау, сюжетлы - рольле уеннар өчен атрибутлар ясау, мавыктыргыч уенчыклар ясау, күргәзмәләр оштыру | Декабрь Январь | Тәрбиче |
| 3. | Укучылар ярдәме белән балалар бакчасы территориясен җыештыру, кардан төрле корылмалар ясау. | Январь | Тәрбиче |

## 11. Административ –хуҗалык эшләре

| № п/п | Эшләнәсе эшләр | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Балалар мебелендәге маркировканы яңарту | август | Бакча мөдире |
| 2. | Яктырту системасыннан һәм судан дөрес һәм экономияле файдалану | ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 3. | Кер юу машиналарын һәм үтүкләрне ремонтлау | сентябрь | Бакча мөдире |
| 4. | Балалар бакчасы территориясендә оештыру эшләре | сентябрь | Бакча мөдире |
| 5. | Төркемне булдыра алган кадәр уенчыклар белән тәэмин итү | ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 6. | Сәхнәләштерү өчен персонаж костюмнары белән тулыландыру | ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 7. | Булдыра алганча куллануга яраксыз хуҗалык инвентарен, савыт-сабаларны яңага алыштыру һәм гамәлдән чыгару | ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 8. | Техник куркынычсызлык кагыйдәләрен төгәл үтәү | ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 9. | Бакчада  косметик ремонт эшләрен башкару | август | Бакча мөдире |

## 12. Сәламәтләндерү, чыныктыру планы

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | ФИЗО почмакларын, спорт участокларын яңарту, атрибутлар белән тулыландыру | даими | мөдир<br>тәрбияче. |
| 2. | Максатчан экскурсияләр оештыру. | даими | Тәрбияче ярдәмчесе, тәрбияче. |
| 3. | Хәрәкәтле уеннар өчен кулланма җиһазлар туплау. | даими | мөдир. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | Физкультура бәйрәмнәре уздыру. | елга ике | Тәрбияче |
| 5. | РҮШ педиатры тарафыннан балаларны тикшерүләр, әңгәмәләр. | график буенча | Тәрбияче |
| 6. | Иртәнге гимнастикаларны, физкультура шөгыльләрен үз югарылыгында үткәрү | даими | тәрбияче |
| 7. | Санитария - гигиена таләпләрен үтәү | даими | Тәрбияче ярдәмчесе, тәрбияче. |
| 8. | Ата-аналар белән балаларның сәламәтлекләре турында әңгәмәләр уздыру. | даими | мөдир тәрбияче |
| 11. | Башлангыч мәктәп укучылары белән берлектә спорт бәйрәмнәре уздыру | елга ике | Укытучы, тәрбияче |
| 12. | Прогулкаларда хәрәкәтле уеннарны тиешенчә үткәрү | даими | тәрбияче |

## 13. Юл кагыйдәләрен өйрәтү буенча эш планы

| № | Чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 3 | Төркем бүлмәсендә һәм ата –аналар өчен “Юл йөрү кагыйдәләре” почмагын җиһазлау | Август | Тәрбияче |
| 4. | Юл кагыйдәләрен өйрәтү шөгыльләре | Елдәвамында тәрбиячнең планнары буенча | Тәрбияче |
| 5. | Юл кагыйдәләрен өйрәтү буенча дидактик уеннар ясау. | Ел дәвамында | Ата-аналар, Тәрбияче |
| 6.. | Стенд материалларын яңартып тору | Даими | Тәрбияче |
| 7. | Экскурсияләр: | тәрбияченең календарь планы буенча | Тәрбияче |
| 8. | Видеофильмнар, слайдлар карау | Ел дәвамында | Тәрбияче |
| 9. | Матур әдәбият уку | шөгыль барышында һәм буш вакытларда | Тәрбияче |

**14. Табигатьне саклау буенча эш планы.**

| № | Эш төре | Үткәрү вакыты | Үткәрүгә җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Республика,район җитәкчелеге карарлары б/н танышу | даими | бакча мөдире |
| 2. | Туган як табигате б/н балаларны таныштыруны дәвам итү. | даими | тәрбиячеләр |
| 3. | Язгы һәм көзге өмәләрдә катнашу | апрель сентябрь | коллектив |
| 4. | Балалар бакчасы ишек алдында гөлләр утырту,үстерү. | Апрель-август | коллектив |
| 5. | “Кызыл китап ни сөйли?” дип исемләнгән чара үткәрү. | август | тәрбияче |
| 6. | Чишмә,сулыклар буена максатчан прогулка. | Май, сентябрь | тәрбияче |
| 7. | Экологик аң алшартларын формалаштыру буенча барлык төркемнәрдә системалы эш алып бару. | даими | тәрбиячеләр |